МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ
И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН
ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ
ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

08.06.2017 № 357

г.Казань

Боерык Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2017 елның 04 июлендә 3991 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2016 елның 21 июнендәге 348 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт вазыйфасын үтәүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында законнарның нигезләмәләрен тормышка ашыру максатларында б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының "Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт вазыйфасын үтәүнең административ регламентын раслау турында" 2016 елның 21 июнендәге 348 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт вазыйфасын үтәүнең административ регламентына кертелә торган, кушымта булып килүче үзгәрешләрне (алга таба – Үзгәрешләр) кертергә.

2. Бу боерыкның, 2017 елның 1 июлендә үз көченә керә торган утыз өченче абзацыннан кала, рәсми рәвештә бастырып чыгарылган көннән башлап үз көченә керүен билгеләргә.

Министр в.б. Н.В. Бутаева

Татарстан Республикасы
Хезмәт, халыкны эш
белән тәэмин итү
һәм социаль яклау
министрлыгының
08.06.2017 № 357
боерыгы белән
расланды

**Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2016 елның 21 июнендәге 348 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт вазыйфасын үтәүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр**

1 бүлектә:

1.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"1.4. Дәүләт вазыйфасы үтәлүне җайга сала торган норматив-хокукый актлар исемлеге:

"Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында" 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – № 294-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 2008, № 52, 6249 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

"Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында" 2013 елның 28 декабрендәге 442-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 2013, № 52, 7007 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

"Аерым эшчәнлек төрләрен лицензияләү турында" 2011 елның 4 маендагы 99-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – № 99-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 2011, № 19, 2716 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

"Персональ мәгълүматлар турында" 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – № 152-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 2006, № 31, 3451 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

"Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында" 1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 1999, № 14, 1650 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасында өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләрне җиткерүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында" 2014 елның 29 декабрендәге 1053 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләрне җиткерүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибе (алга таба – ТР МК № 1053 карары белән расланган Өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибе) ("Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы" журналы, 2015, № 7-8, 0201 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасында социаль хезмәтләрне җиткерүчеләр реестрын һәм алучылар регистрын формалаштыру һәм алып бару турында" 2014 елның 23 декабрендәге 1012 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр алучыларның регистрын формалаштыру һәм алып бару тәртибе (алга таба – ТР МК № 1012 карары белән расланган Регистр формалаштыру һәм алып бару тәртибе) ("Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы" журналы, 2015, № 3, 0093 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Социаль хезмәтләрне күрсәткән өчен түләү күләмен һәм аны алу тәртибен раслау турында" 2014 елның 29 ноябрендәге 927 номерлы карары ("Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы" журналы, 2014, № 91-92, 2850 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт вазыйфаларын үтәүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында" 2012 елның 31 декабрендәге 1192 номерлы карары ("Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы" журналы, 2013, № 7, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып).";

1.8.1 пунктта:

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"тикшерү үткәрү турында боерык (әмернамә) кабул ителгәннән соң юридик заттан, шәхси эшкуардан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында кирәкле документларны һәм (яки) мәгълүматларны сорарга, урынга чыгып тикшерү үткәргәндә, әгәр дә урынга чыгып тикшерү алдыннан документар тикшерү үткәрелмәгән булса, социаль хезмәтләрне җиткерүченең җитәкчесеннән, бүтән вазыйфаи затыннан яисә вәкаләтле вәкиленнән тикшерү предметына кагыла торган мәсьәләләр буенча документлар һәм материаллар, язмача аңлатмалар алырга;";

түбәндәге эчтәлекле алтынчы абзац өстәргә:

"түләүсез нигездә, шул исәптән электрон рәвештә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән исемлеккә кертелгән документларны һәм (яки)

мәгълүматны шушы документлар һәм (яки) мәгълүмат белән эш итүче бүтән дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалардан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән чорларда һәм тәртиптә соратырга һәм алырга;";

1.8.3 пунктта:

өченче абзацта: "һәм Россия Федерациясе законнарына туры килми торган" сүзләрен ", шулай ук зарури үтәлеше Россия Федерациясе законнарында каралмаган норматив документларның таләпләре үтәлешен" сүзләренә алмаштырырга;

унберенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"социаль хезмәтләрне җиткерүчедән тикшерүне үткәрә башлау датасына кадәр документлар, мәгълүматлар таләп итәргә. Министрлык тикшерү үткәрү турында боерык (әмернамә) кабул ителгәч кирәкле документларны һәм (яки) мәгълүматларны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында соратырга хокуклы.";

2 бүлектә:

2.1.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2.1.5. Министрлыкның рәсми сайтында, Министрлыкның гражданнарны кабул итү гамәлгә ашырыла торган бүлмәләрендәге мәгълүмат стендларында дәүләт вазыйфасын үтәү мәсьәләләре буенча түбәндәге мәгълүматлар урнаштырыла:

1) урнашу урыны, элемтә телефоннары, Интернет челтәрендә рәсми сайтлар, электрон почта адреслары турындагы белешмәләр;

2) Россия Федерациясе законнарының һәм Татарстан Республикасы законнарының дәүләт вазыйфасын үтәү тәртибенә кагыла торган төп нигезләмәләре турындагы мәгълүмат;

3) кушымталары белән бергә шушы Административ регламент тексты;

4) дәүләт вазыйфасын үтәү барышы турында мәгълүмат;

5) дәүләт вазыйфасын үтәүче вазыйфаи затларның карарларын, гамәлләрен (гамәл кылмауларын) шикаять кылу тәртибе;

6) бозуларны профилактикалауның ел саен раслана торган программасы;

7) үтәлешен бәяләү контрольлек предметы булган зарури таләпләрне үз эченә ала торган норматив-хокукый актларның яисә аларның аерым өлешләренең исемлеге, шулай ук тиешле норматив-хокукый актларның текстлары;

8) зарури таләпләрне үтәү мәсьәләләре буенча, шулай ук зарури таләпләрне үтәү буенча бастырып чыгарылган кулланмалар турында мәгълүмат, семинарлар һәм конференцияләр үткәрелүе, массакүләм мәгълүмат чараларында аңлату эшләре турында белешмәләр, бүтән ысуллар белән урнаштырылган бүтән мәгълүматлар турында белешмәләр. Зарури таләпләр үзгәртелгән очракта, гамәлдәге актларга кертелгән үзгәрешләрдәге зарури таләпләрне билгели торган яңа норматив-хокукый актларның эчтәлеге, аларның гамәлгә керү вакытлары һәм тәртибе турында аңлатмалар, шулай ук зарури таләпләрне кертүгә һәм аларның үтәлешен тәэмин итүгә юнәлдерелгән, зарури оештыру, техник чараларны үткәрү турында киңәшләр урнаштырыла;

9) дәүләт вазыйфасын гамәлгә ашыру буенча даими, елына бер мәртәбәдән сирәк булмаган рәвештә башкарыла торган тәҗрибә гомумиләштерү буенча

белешмәләр, шул исәптән зарури таләпләрне бозуның иң еш очрый торган очракларын күрсәтеп, юридик затлар, шәхси эшкуарлар тарафыннан мондый бозуларга юл куймау максатларында күрелергә тиешле чараларга кагылышлы киңәшләр белән.";

2.4.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2.4.2. Социаль хезмәтләрне җиткерүчегә карата планнан тыш тикшерү үткәрү өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

1) Министрлык тарафыннан элегрәк бирелгән зарури таләпләрнең ачыкланган бозуларын юкка чыгару турында күрсәтмәнең социаль хезмәтләрне җиткерүче тарафыннан үтәү вакыты узу;

2) Түбәндәге фактлар турында Министрлыкка гражданнардан, шул исәптән шәхси эшкуарлардан, юридик затлардан килгән мөрәҗәгатьләрне һәм гаризаларны, дәүләт хакимиятеннән, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан килгән мәгълүматларны карап тикшерү яисә беренчел тикшерү нәтиҗәләре буенча Министрлыкның вазыйфаи затының дәлилле йогынты акты:

- гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә зыян килү куркынычы барлыкка килү;

- гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә зыян килү;

- кулланучыларның хокуклары бозылу (хокуклары бозылган кулланучылар, гражданнар хокукларын яклау өлкәсендә федераль дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыручы органга мөрәҗәгать иткән очракта, мөрәҗәгать итүченең үзенең бозылган хокукларын яклау (торгызу) буенча юридик затка, шәхси эшкуарга мөрәҗәгать итүе һәм мондый мөрәҗәгатьнең карап тикшерелмәгән булуы яисә мөрәҗәгать итүченең таләпләре канәгатьләндерелмәгән булу шарты белән);

3) Россия Федерациясе Президенты, Россия Федерациясе Хөкүмәте йөкләмәләренә туры китереп һәм прокурорның прокуратура органнарына килгән материаллар һәм мөрәҗәгатьләр буенча законнар үтәлешенә күзәтчелек итү кысаларында планнан тыш тикшерү үткәрү турындагы таләбе нигезендә чыгарылган министр боерыгы (әмернамәсе).";

түбәндәге эчтәлекле 2.4.3-2.4.9 пунктларын өстәргә:

"2.4.3. Социаль хезмәтләрне җиткерүчеләргә планнан тыш урынга чыгып тикшерү шушы Административ регламентның 2.4.2 пунктындагы 2 пунктчаның икенче һәм өченче абзацларында күрсәтелгән нигезләрдә, шушы социаль хезмәтләрне җиткерүчеләрнең эшчәнлекләрен гамәлгә ашыру урыны буенча прокуратура органы белән килештерелгәч үткәрелергә мөмкин.

2.4.4. Министрлыкка мөрәҗәгать итүченең затын билгеләргә мөмкинлек бирми торган мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, шулай ук шушы Административ регламентның 2.4.2 пунктының 2 пунктчасында күрсәтелгән фактлар турында белешмәләре булмаган мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигез булып хезмәт итә алмыйлар. Әгәр дә мөрәҗәгатьтә яки гаризада бәян ителгән мәгълүмат, шушы Административ регламентның 2.4.2 пунктындагы 2 пунктчасы нигезендә планнан тыш тикшерү үткәрүнең нигезе була алса, Министрлыкның вазыйфаи заты, аның мөрәҗәгатьнең яки гаризаның авторына карата нигезле шикләре булганда, мөрәҗәгать итүче затны билгеләү буенча гакыллы чаралар күрергә бурычлы. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан электрон документлар

рәвешендә җибәрелгән мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, аларның мөрәҗәгать итүче тарафыннан бары тик бердәй идентефикацияләү һәм аутентификацияләү системасында мөрәҗәгать итүченең мәҗбүри авторлаштырылуын күздә тотучы мәгълүмати-коммуникация технологияләре чараларыннан файдаланып җибәрелгән булу шарты белән генә, планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигез булып хезмәт итә алалар.

2.4.5. Шушы Административ регламентның 2.4.2 пунктында күрсәтелгән фактлар турындагы мөрәҗәгатьләрне һәм гаризаларны, мәгълүматларны карап тикшергәндә элегрәк килгән, охшаш мөрәҗәгатьләрне һәм гаризаларны, мәгълүматларны карап тикшерү нәтиҗәләре, шулай ук тиешле юридик затларга, шәхси эшкуарларга карата элегрәк үткәрелгән контрольлек чараларының нәтиҗәләре исәпкә алынырга тиеш.

2.4.6. Зарури таләпләр бозылуга юл куйган зат турында дөрес мәгълүмат, зарури таләпләрне бозу турында яисә шушы Административ регламентның 2.4.2 пунктында күрсәтелгән фактлар турында җитәрлек мәгълүматлар булмаганда, Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи затлары тарафыннан килгән мәгълүматка беренчел тикшерү үткәрелергә мөмкин. Беренчел тикшерүне үткәрү барышында гаризаны һәм мөрәҗәгатьне җибәргән, мәгълүматлар җиткергән затлардан өстәмә белешмәләр һәм материаллар (шул исәптән телдән тәртиптә) соратып алу буенча чаралар күрелә, социаль хезмәтләрне җиткерүченең Министрлык карамагында булган документлары карап тикшерелә, зарурлык булганда, социаль хезмәтләрне җиткерүче белән хезмәттәшлек итмичә генә һәм күрсәтелгән затларга мәгълүматлар тапшыру һәм Министрлык таләпләрен үтәү буенча бурычлар йөкләмичә генә контрольлек буенча чаралар үткәрелә. Килгән мәгълүматка беренчел тикшерү кысаларында социаль хезмәтләрне җиткерүчедән алынган мәгълүматка карата аңлатмалар соратып алынырга мөмкин, ләкин мондый аңлатмаларны һәм башка төрле документларны тапшыру мәҗбүри булып саналмый.

2.4.7. Беренчел тикшерү нәтиҗәләре буенча зарури таләпләр бозылуга юл куйган затлар ачыкланганда, зарури таләпләрне бозу турында яисә шушы Административ регламентның 2.4.2 пунктында күрсәтелгән фактлар турында җитәрлек күләмдә мәгълүматлар алынганда, Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи заты, шушы Административ регламентның 2.4.2 пунктының 2 пунктчасында күрсәтелгән нигезләр буенча, планнан тыш тикшерү үткәрү турында дәлилле йогынты актын әзерли. Беренчел тикшерү нәтиҗәләре буенча социаль хезмәтләр җиткерүчене җаваплылыкка тарту буенча чаралар күрелми.

2.4.8. Министр (министр урынбасары) карары буенча, әгәр дә тиешле тикшерүне башлаганнан соң, аны оештыру өчен нигез булган мөрәҗәгатьнең яки гаризаның аноним булуы ачыкланса, яисә мөрәҗәгатьтә яки гаризада белә торып ялган белешмәләр булуы ачыкланса, беренчел тикшерү, планнан тыш тикшерү туктатыла.

2.4.9. Әгәр дә гаризаларда, мөрәҗәгатьләрдә белә торып ялган белешмәләр күрсәтелгән булса, Министрлык гражданиннан, шул исәптән шәхси эшкуарлардан, юридик затлардан, күрсәтелгән затлардан килгән гаризаларны, мөрәҗәгатьләрне карауга бәйле рәвештә, Министрлык тарафыннан тотылган чыгымнарны түләттерү турында судка дәгъва белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

2.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2.6. 294-ФЗ номерлы Федераль законны бозган өчен социаль хезмәтләрне җиткерүчеләрнең җаваплы булуы.

294-ФЗ номерлы Федераль закон бозылуга юл куйган, тикшерүләрне үткәрүгә нигезсез рәвештә каршы төшүче, тикшерүләрне үткәрүдән качып йөрүче һәм (яки) билгеләнгән чорларда Министрлыкның ачыкланган зарури таләпләрне бозуларны юкка чыгару турында күрсәтмәсен үтәмәүче социаль хезмәтләрне җиткерүчеләр, аларның җитәкчеләре, бүтән вазыйфаи затлары яисә вәкаләтле вәкилләре Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы була.";

3 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"3.1. Үтәлеше Министрлык тарафыннан тикшереп торыла торган, социаль хезмәтләрне җиткерүчеләргә карата белдерелүче зарури таләпләрнең исемлеге, аларны билгели торган норматив-хокукый актларның исемлеге, тикшерү барышында социаль хезмәтләрне җиткерүчеләр тарафыннан күрсәтелә торган документларның исемлеге 1 таблицада китерелде.

**1 таблица – Социаль хезмәтләрне җиткерүчеләргә белдерелә торган зарури таләпләр исемлеге**

| Зарури таләпләр исемлеге | Зарури таләпне билгели торган норматив-хокукый акт | Тикшерү үткәргәндә юридик затлар, шәхси эшкуарлар тарафыннан күрсәтелә торган документлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. Тикшереп торыла торган объектлар: социаль хезмәтләрнең барлык җиткерүчеләре (социаль хезмәт күрсәтүнең стационар рәвешендә, социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар рәвешендә, өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтүче социаль хезмәтләр җиткерүчеләр) | | |
| 1.1. Эшчәнлекне гамәлдәге норматив-хокукый актлар нигезендә гамәлгә ашыру, шул исәптән лицензияле булу. | № 442-ФЗ Федераль законның 12 статьясының 1 өлешендәге 1 пункты.<br>ТР МК № 1100 карары белән расланган Стационар рәвештә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенең 1.3.1 пункты.<br>ТР МК № 1101 карары белән расланган Социаль хезмәт күрсәтүнең | Социаль хезмәтләрне күрсәтүнең аерым программасында билгеләнгән социаль хезмәтләрне күрсәтү өчен матди-техник базаның, квалификацияле кадрларның булуын таныклый торган документлар (алга таба – ИППСУ). |

| | | |
|---|---|---|
| | ярымстационар рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенең 1.3.1 пункты. | |
| 1.2. Социаль хезмәтләрне алучыларга ИППСУ нигезендә һәм социаль хезмәтләрне алучылар яисә № 442-ФЗ Федераль закон нигезендә аларның законлы вәкилләре белән төзелгән шартнамәләрнең шартлары буенча социаль хезмәтләр күрсәтү. | №442-ФЗ Федераль законның 12 статьясының 1 өлешендәге 2 пункты, 16 статьясының 3 өлеше, 17 статьясы. | Социаль хезмәтләрне күрсәтүгә шартанмәләр; ИППСУ буенча социаль хезмәтләрне алучыларның формалаштырылган шәхси эшләре. |
| 1.3. Ашыгыч социаль хезмәтләр күрсәтү. | № 442-ФЗ Федераль законның 12 статьясының 1 өлешендәге 3 пункты, 21 статьясы. | Социаль хезмәтләрне алучының гаризасы, ашыгыч социаль хезмәтләр күрсәтелү турында бу хезмәтләрне алучы һәм җиткерүче турында, күрсәтелгән ашыгыч социаль хезмәтләрнең төрләре, вакытлары, датасы һәм аларны күрсәтү шартлары турында белешмәләре булган акт. Ашыгыч социаль хезмәтләр күрсәтелү турында акт. |
| 1.4. Социаль хезмәтләрне алучыларга яисә аларның законлы вәкилләренә үтемле рәвештә бушлай нигездә аларның хокуклары һәм бурычлары турында, социаль хезмәтләрнең төрләре, аларны күрсәтү вакытлары, тәртибе һәм шартлары турында, бу хезмәтләргә тарифлар | № 442-ФЗ Федераль законның 12 статьясының 1 өлешендәге 4 пункты, 13 статьясы. | Социаль хезмәтләрне җиткерүченең социаль хезмәтләрнең төрләре, аларны күрсәтү вакытлары, тәртибе һәм шартлары турында, |

| | | |
|---|---|---|
| турында һәм социаль хезмәтләрне алучы өчен аларның бәясе хакында яисә аларны бушлай нигездә алу мөмкинлеге турында мәгълүмат бирү. | | бу хезмәтләргә тарифлар турында һәм социаль хезмәтләрне алучы өчен аларның бәясе турында яисә аларны бушлай нигездә алу мөмкинлеге турында локаль актлары. |
| 1.5. Персональ мәгълүматларны яклау турында Россия Федерациясенең персональ мәгълүматлар турындагы законнарында билгеләнгән таләпләр нигезендә социаль хезмәтләрне алучылар турындагы мәгълүматтан файдалануга карата таләпләрне үтәү. | № 442-ФЗ Федераль законның 12 статьясының 1 өлешендәге 5 пункты.<br>№ 152-ФЗ Федераль закон. | Социаль хезмәтләрне алучыларның шәхси эшләре. |
| 1.6. Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр җиткерүчеләр реестрына кертелгән социаль хезмәтләрне җиткерүчеләр тарафыннан Татарстан Республикасында социаль хезмәтләрне алучыларның регистрын формалаштыру өчен мәгълүматларны Министрлыкка үз вакытында тапшыру. | № 442-ФЗ Федераль законның 12 статьясының 1 өлешендәге 6 пункты, 26 статьясы.<br>ТР МК № 1012 карары белән расланган Регистрны формалаштыру һәм алып бару тәртибенең 5 пункты. | Социаль хезмәтләрне алучыларның шәхси эшләре (социаль хезмәтләрне алучылар регистрында социаль хезмәтләрне алучылар турында мәгълүмат булу). |
| 1.7. Ведомствоара хезмәттәшлек нигезендә балигълык яшенә җитмәгән балаларның ата-аналарын, опекуннарын, попечительләрен, бүтән законлы вәкилләрен кертеп, гражданнарны социаль озата баруны, зарурлык булганда, медицина, психологик, педагогик, юридик, социаль яисә бүтән характердагы, шул исәптән мондый ярдәмне күрсәтә торган оешмаларны җәлеп итеп гамәлгә ашыру. | № 442-ФЗ Федераль законның 12 статьясының 1 өлешендәге 7 пункты, 22, 28 статьялары. | ИППСУ (социаль озата бару буенча аларда чагылдырылган чаралар белән). |

| | | |
|---|---|---|
| 1.8. Зарурлык булганда, социаль хезмәтләрне алучыларга Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә федераль медик-сациаль экспертиза учреждениеләре тарафыннан үткәрелә торган медик-социаль экспертизаны (алга таба – МСЭ) үткәндә булышуны тәэмин итү, шул исәптән инвалидлык группасын билгеләү, үзгәртү максатларында, яисә инвалидны тернәкләндерүнең аерым программасын төзегәндә гражданинга шаһит булу, МСЭ юллама алу максаты белән медицина оешмаларында медицина ягыннан шаһитлык үтүдә булышу, социаль хезмәтләр алучыны МСЭ үткәрелү урынына транспорт белән тәэмин итүдә булышу, тернәкләндерүнең аерым программасын тормышка ашыруда ярдәм күрсәтү һәм башкалар. | № 442-ФЗ Федераль законның 12 статьясының 1 өлешендәге 8 пункты. | ИППСУ (МСЭ үтүдә шартлар тудыру буенча аларда чагылдырылган чаралар белән). |
| 1.9. Социаль хезмәтләрне ышанычлы күрсәтү. | ТР МК № 1100 карары белән расланган Стационар рәвештә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенең 1.3.2-1.3.4 пунктлары.<br>ТР МК № 1101 карары белән расланган Ярымстационар рәвештә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенең 1.3.2-1.3.4 пунктлары.<br>ТР МК № 1053 карары белән расланган Өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә | Социаль хезмәтләрне күрсәткәндә ышанычлылык, кулланыла торган җайланманың, материалларның нормаларга туры килүе турындагы документлар;<br>социаль хезмәтләрне күрсәтү буенча кулланмалар, кагыйдәләр, технологияләр һәм методикалар;<br>җитештерү контроле нәтиҗәләре, шул |

| | | |
|---|---|---|
| | социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенең 4.1 пункты. | исәптән лаборатор тикшеренүләр һәм сынаулар үткәрү юлы белән. |
| 1.10. Социаль хезмәтләрне сыйфатлы күрсәтү өчен кирәкле персонал булу. | ТР МК № 1100 карары белән расланган Стационар рәвештә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенең 1.4.1 пункты;<br>ТР МК № 1101 карары белән расланган Ярымстационар рәвештә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенең 1.4.1 пункты;<br>ТР МК № 1053 карары белән расланган Өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенең 6.3.1 пункты. | Штат расписаниеcе. |
| 1.11. Социаль хезмәтләр күрсәтүне туктатып торган яисә туктатканда нигезләрнең үтәлеше | ТР МК № 1100 карары белән расланган Стационар рәвештә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенең 1.6 пункты;<br>ТР МК № 1101 карары белән расланган Ярымстационар рәвештә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенең 1.6 пункты;<br>ТР МК № 1053 карары белән расланган Өйдә | Социаль хезмәтләрне алучыларның шәхси эшләре. |

| | | |
|---|---|---|
| | социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенең 4.6 пункты. | |
| 1.12. Күрсәтелә торган социаль хезмәтләрнең сыйфаты билгеләнгән таләпләргә туры килү | ТР МК № 1100 карары белән расланган Стационар рәвештә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенең 1.7 пункты;<br>ТР МК № 1101 карары белән расланган Ярымстационар рәвештә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенең 1.7 пункты;<br>ТР МК № 1053 карары белән расланган Өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенең 6.4 пункты. | Социаль хезмәтләрне алучыларның шәхси эшләре. |
| 1.13. Социаль хезмәтләрне алучыларның шәхси әйберләре һәм кыйммәтләре саклануны тәэмин итү | № 442-ФЗ Федераль законның 12 статьясының 1 өлешендәге 12 пункты;<br>ТР МК № 1100 карары белән расланган Стационар рәвештә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенең 1 бүлеге;<br>ТР МК № 1101 карары белән расланган Ярымстационар рәвештә социаль хезмәтләр күрсәтү | Социаль хезмәтләрне алучыларның шәхси әйберләре һәм кыйммәтләре саклануны тәэмин итү буенча локаль актлар. |

| | | |
|---|---|---|
| | тәртибенең 1 бүлеге; ТР МК № 1053 карары белән расланган Өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенең 4.1 пункты. | |
| 1.14. Социаль хезмәтләрнең билгеләнгән исемлеге һәм стандартлары нигезендә социаль хезмәтләр күрсәтү буенча таләпләр үтәлеше. | ТР МК № 1100 карары белән расланган Стационар рәвештә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә 1 нче кушымта; ТР МК № 1101 карары белән расланган Ярымстационар рәвештә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә 1 нче кушымта; ТР МК № 1053 карары белән расланган Өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенең 1.3 пункты, кушымтасы. | Социаль хезмәтләр күрсәтүгә шартнамәләр; социаль хезмәтләрне алучыларның шәхси эшләре. |
| 1.15. Социаль хезмәтләрне күрсәткән өчен түләү күләмен хисаплауның дөрес булуы өлешендәге контрольдән кала, социаль хезмәтләрне түләү, өлешчә түләү яисә бушлай нигездә күрсәтү буенча таләпләрне үтәү. | ТР МК № 1100 карары белән расланган Стационар рәвештә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенең 2.2, 3.2, 4.2, 5.2, 6.2, 7.2 пунктлары; ТР МК № 1101 карары белән расланган Ярымстационар | Социаль хезмәтләр күрсәтүгә шартнамәләр. |

| | | |
|---|---|---|
| | рәвештә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенең 2.2, 3.2, 4.2, 5.2 пунктлары;<br>ТР МК № 1053 карары белән расланган Өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенең 3.1-3.5 пунктлары. | |
| 1.16. Социаль хезмәтләр күрсәтүнең стационар һәм ярымстационар рәвешендә социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында хезмәтләр алганда социаль хезмәтләрне алучыларга элемтә хезмәтләреннән, шул исәптән "Интернет" челтәреннән һәм почта элемтәсе хезмәтләреннән файдалану мөмкинлеген бирү. | № 442-ФЗ Федераль законның 12 статьясының 1 өлешендәге 9 пункты. | Социаль хезмәтләр җиткерүченең локаль актлары. |
| 1.17. Социаль хезмәт күрсәтү оешмасында яшәүче ир белән хатынга изоляцияләнгән торак бүлмә бирү. | № 442-ФЗ Федераль законның 12 статьясының 1 өлешендәге 10 пункты. | Социаль хезмәтләр җиткерүченең локаль актлары. |
| 1.18. Социаль хезмәтләр алучыларны алар янына законлы вәкилләре, адвокатлары, нотариуслар, иҗтимагый һәм (яисә) бүтән оешмаларның вәкилләре, руханиларның, шулай ук туганнарының һәм башка затларның көндезге һәм кичке вакытта ирекле рәвештә килә алу мөмкинлеген тәэмин итү. | № 442-ФЗ Федераль законның 12 статьясының 1 өлешендәге 11 пункты. | Социаль хезмәтләр җиткерүченең локаль актлары.<br>Эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре. |

3.2. Зарури таләпләр бозылуны профилактикалау максатларында Министрлык шушы Административ регламентның 3.3-3.15 пунктлары нигезендә зарури таләпләрне бозу ярамаганлыгы турында кисәтүләр бирә.

3.3. Федераль законда башкача билгеләнмәгән булу шарты белән, Министрлыкта зарури таләпләрне бозуга әзерләнүләр яисә бозу билгеләре турында юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән хезмәттәшлек итмичә генә гамәлгә ашырыла

торган контрольлек чараларын тормышка ашыру барышында алынган яисә килгән мөрәҗәгатьләрдә һәм гаризаларда (авторлыгы расланмаган мөрәҗәгатьләрдән һәм гаризалардан тыш), дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан алынган мәгълүматлардагы белешмәләр булган очракта, әгәр дә зарури таләпләрне, муниципаль-хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне бозуның гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә зыян, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә тирәлеккә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни ядкәрләргә), дәүләт иминлегенә зыян китерүе, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килүгә китерүе яисә күрсәтелгән нәтиҗәләрнең турыдан-туры куркынычын барлыкка китерүе турында расланган белешмәләр булмаса, әгәр дә юридик зат, шәхси эшкуар элегрәк тиешле таләпләрне бозган өчен җаваплылыкка тартылмаган булса, Министрлык юридик затка, шәхси эшкуарга зарури таләпләрне бозуның ярамаганлыгы турында кисәтү белдерә һәм юридик затка, шәхси эшкуарга зарури таләпләрнең үтәлешен тәэмин итү буенча чаралар күрергә һәм бу хакта шул кисәтүдә билгеләнгән чорда Министрлыкка хәбәр итәргә тәкъдим итә.

3.4. Кисәтү җибәрү турындагы карар министр (министрның урынбасары) яисә Министрлык боерыгы нигезендә вәкаләт бирелгән бүтән вазыйфаи зат тарафыннан Министрлыкның вазыйфаи заты тәкъдимнәре нигезендә шушы Административ регламентның 3.3 пунктында күрсәтелгән мәгълүматлар булганда кабул ителә.

3.5. Кисәтүне төзү һәм җибәрү Министрлыкның вазыйфаи заты шушы Административ регламентның 3.3 пунктында күрсәтелгән мәгълүматларны алган көннән башлап 30 календарь көненнән соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

3.6. Күрсәтмәдә түбәндәгеләр күрсәтелә:

- Министрлыкның исеме;
- кисәтүнең датасы һәм номеры;
- юридик затның аталышы, шәхси эшкуарның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта);
- зарури таләпләргә, норматив-хокукый актларга күрсәтү, аларның күрсәтелгән таләпләрне күздә тотучы структур берәмлекләрен дә кертеп;
- юридик затның, шәхси эшкуарның кайсы гамәлләре (гамәл кылмавы) зарури таләпләр бозылуга китерүе яисә китерергә мөмкин булуы турында мәгълүмат;
- юридик затка, шәхси эшкуарга зарури таләпләр үтәлүне тәэмин итү буенча чаралар күрүне тәкъдим итү;
- юридик затка, шәхси эшкуарга кисәтүнең үтәлеше турында Министрлыкка хәбәрләмә җибәрү турында тәкъдим итү;
- юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан кисәтүнең үтәлеше турында хәбәрләмә җибәрү вакыты (кисәтү җибәрелгән көннән башлап кимендә 60 календарь көне);
- почта адресын һәм электрон почта адресын кертеп, Министрлыкның элемтә белешмәләре, шулай ук ризасызлыклар, кисәтүнең үтәлеше турындагы хәбәрләмәне бирүнең мөмкин булган бүтән ысуллары.

3.7. Кисәтүдә юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан белешмәләр һәм документлар тапшырылу турында таләп була алмый.

3.8. Кисәтү кәгазьдә кулга тапшыру турындагы хәбәрләмә белән почта аша заказлы хат итеп яисә, "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәреннән

файдаланып, шушы Административ регламентның 3.4 пунктында күрсәтелгән кисәтүне җибәрү турында карар кабул иткән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы куелган электрон документ рәвешендә җибәрүне дә кертеп, шул исәптән юридик затның, шәхси эшкуарның, тиешенчә, Бердәй дәүләт юридик затлар реестрында, Бердәй дәүләт шәхси эшкуарлар реестрында күрсәтелгән яисә юридик затның, шәхси эшкуарның рәсми сайтында Россия Федерациясе законнары нигезендә зарури рәвештә урнаштырылырга тиешле мәгълүматлар составында урнаштырылган электрон почта адресы буенча, яисә "Бердәй дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы" федераль дәүләт мәгълүмат системасы ярдәмендә, юридик зат, шәхси эшкуар өчен мөмкин булган бүтән ысул белән җибәрелә.

3.9. Кисәтүне карау нәтиҗәләре буенча юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан Министрлыкка ризасызлыклар тапшырылырга мөмкин.

3.10. Ризасызлыкларда түбәндәгеләр күрсәтелә:

- юридик затның аталышы, шәхси эшкуарның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта);

- салым түләүче - юридик затның, шәхси эшкуарның индентификацияләү номеры;

- юридик затның, шәхси эшкуарның адресына җибәрелгән кисәтүнең датасы һәм номеры;

- юридик затның, шәхси эшкуарның зарури таләпләр бозылуга китерә торган яки китерергә мөмкин буган кисәтүдә күрсәтелгән гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата позицияне нигезләү.

3.11. Ризасызлыклар Министрлыкка юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан кәгазьдә почта аша хат итеп, яисә шәхси эшкуарның, юридик зат исеменнән гамәл кылу вәкаләте бирелгән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә кисәтүдә күрсәтелгән Министрлыкның электрон почта адресына, яисә кисәтүдә күрсәтелгән бүтән ысуллар белән җибәрелә.

3.12. Министрлык ризасызлыкларны карап тикшерә, карап тикшерү йомгаклары буенча юридик затка, шәхси эшкуарга ризасызлыкларны алган көннән башлап 20 эш көне эчендә шушы Административ регаментның 3.8 пунктында билгеләнгән тәртиптә җавап җибәрә. Ризасызлыкларны карап тикшерү нәтиҗәләре Министрлык тарафыннан зарури таләпләр бозылуны профилактикалау буенча чараларны оештыру һәм үткәрү максатларында һәм юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын һәм ирекләрен чикләүгә бәйле булмаган бүтән максатларда файдаланыла.

3.13. Ризасызлыклар булмаганда, юридик зат, шәхси эшкуар кисәтүдә күрсәтелгән чорда Министрлыкка кисәтүне үтәү турында хәбәрләмә җибәрә.

3.14. Кисәтүне үтәү турындагы хәбәрләмәдә түбәндәгеләр күрсәтелә:

- юридик затның аталышы, шәхси эшкуарның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта);

- салым түләүче - юридик затның, шәхси эшкуарның индентификацияләү номеры;

- юридик затның, шәхси эшкуарның адресына җибәрелгән кисәтүнең датасы һәм номеры;

- кисәтүне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча зарури таләпләр үтәлешен тәэмин итү буенча күрелгән чаралар турында мәгълүматлар.

3.15. Хәбәрләмә Министрлыкка юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан кәгазьдә почта аша хат итеп, яисә шәхси эшкуарның, юридик зат исеменнән гамәл кылу вәкаләте бирелгән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә кисәтүдә күрсәтелгән Министрлыкның электрон почта адресына, яисә кисәтүдә күрсәтелгән бүтән ысуллар белән җибәрелә.";

5 бүлектә:

5.2.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"5.2.2. Еллык план 294-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Бүлек тарафыннан эшләнә. Еллык планны әзерләү, шул исәптән аны прокуратура органнарына тапшыру һәм прокуратура органнары белән килештерү тәртибе һәм вакытлары, шулай ук еллык планның типик рәвеше РФ Хөкүмәтенең 489 номерлы карары белән расланан Дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль органнары тарафыннан юридик затларга һәм шәхси эшкуарларга планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планнарын әзерләү кагыйдәләрендә билгеләнгән.

Социаль хезмәтләр җиткерүчене планлы тикшерүне еллык планга кертү өчен шушы Административ регламентның 2.4.1 пунктында күрсәтелгән очраклар нигез булып тора.";

5.2.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"5.2.4. Еллык планны әзерләү буенча җаваплы башкаручы түбәндәге административ гамәлләрне гамәлгә ашыра:

- зарурлык булганда Федераль салым хезмәтеннән, шул исәптән электрон рәвештә, түбәндәге документларны һәм (яки) документларны шушы Административ регламентның 1.8.1 пунктындагы алтынчы абзацы һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 724-р номерлы боерыгы таләпләре нигезендә сората һәм ала:

бердәй дәүләт юридик затлар реестрыннан белешмәләр;

бердәй дәүләт шәхси эшкуарлар реестрыннан белешмәләр;

алдагы календарь елында хезмәткәрләрнең уртача исемлек саны турында белешмәләр;

бердәй кече һәм урта эшкуарлык субъектлары реестрыннан белешмәләр;

- билгеләнгән рәвештә еллык план проектын төзи;

- аны Бүлек башлыгы, министр белән килештерә;

үтәү вакыты: планлы тикшерүләрне үткәргән елдан соң килүче елның 23 августыннан да соңга калмыйча;

- еллык план проектын карап тикшерү өчен аларга карата планлы тикшерүләрне үткәрү планлаштырылган социаль хезмәтләрне җиткерүчеләрнең тору урыны буенча прокуратура органына кәгазьдә (күчермәсен электрон рәвештә теркәп) кулга тапшыру турында хәбәрләмә белән почта аша заказлы хат итеп яисә "Электрон имза турында" 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза (алга таба – көчәйтелгән квалификацияле электрон имза) белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрә;

үтәү вакыты: планлы тикшерүләрне үткәрү елыннан соң килүче елның 1 сентябренә кадәр.";

5.2.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"5.2.7. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 489 номерлы карарында билгеләнгән очракларда дәлилләүче документлар (Бердәй дәүләт юридик затлар реестрыннан яисә Бердәй дәүләт шәхси эшкуарлар реестрыннан юридик затны, шәхси эшкуарны дәүләт теркәвенә алу, ликвидацияләү (реестрдан төшереп калдыру) турында язу теркәлүе турында өземтәләр) булганда еллык планга үзгәрешләр кертү рөхсәт ителә.

Еллык планга үзгәрешләр кертү министр боерыгы нигезендә гамәлгә ашырыла. Кертелгән үзгәрешләр турындагы белешмәләр билгеләнгән тәртиптә тиешле прокуратура органына аларны керткән көннән башлап 10 көнлек чорда җибәрелә һәм Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырыла.";

5.3.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"5.3.1. Еллык план нигезендә планлы тикшерүне үткәрү вакытларының җитүе яисә шушы Административ регламентның 2.4.2 пунктында каралаган планнан тыш тикшерүне үткәрү өчен нигезләр булу административ процедураны башлап җибәрү өчен нигез булып тора.

Планнан тыш тикшерүне үткәрү өчен шушы Административ регламентның 2.4.2 пунктындагы 2 пунктчасында күрсәтелгән нигезләр барлыкка килгән очракта Министрлыкның килгән мөрәҗәгатьне, гаризаны яисә мәгълүматны карап тикшерүгә вәкаләт бирелгән вазыйфаи заты шушы Административ регламентның 2.4.3-2.4.9 пунктларында бәян ителгән таләпләр нигезендә түбәндәге гамәлләрне гамәлгә ашыра:

- мөрәҗәгать итүче затны ачыклау буенча гакыллы чаралар күрә;

- шуңа охшаш, элегрәк килгән мөрәҗәгатьләрнең һәм гаризаларның нәтиҗәләрен, мәгълүматларны, шулай ук тиешле юридик затларга, шәхси эшкуарларга карата элегрәк үткәрелгән контрольлек чараларының нәтиҗәләрен карап тикшерә;

- килгән мәгълүматка башлангыч тикшерүне үткәрә;

- зарурлык булганда юридик зат, шәхси эшкуар белән хезмәттәшлек итмичә генә һәм күрсәтелгән затларга мәгълүмат тапшыру һәм Министрлык таләпләрен үтәү буенча бурычлар йөкләмичә генә гамәлгә ашырыла торган контрольлек чараларын үткәрә;

- шушы Административ регламентның 2.4.2 пунктының 2 пунктчасында күрсәтелгән нигезләрдә планнан тыш тикшерү билгеләү турында дәлилле йогынты актын әзерли.";

5.3.4.1 пунктчасының беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"5.3.4.1. Тикшерүне үткәрү турындагы карар Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы белән расланган тикшерү үткәрү турында әмернамәнең яисә боерыкның типик рәвешенә туры китереп, министрның (министр урынбасарының) тикшерү үткәрү турындагы боерыгы (әмернамәсе) белән рәсмиләштерелә.";

5.3.4.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"5.3.4.2. Тикшерү үткәрү турындагы боерыкта (әмернамәдә) түбәндәгеләр күрсәтелә:

- Министрлыкның исеме, шулай ук дәүләт контроленең (күзәтчелегенең) төре (төрләре);

- тикшерүне үткәрүгә вәкаләт бирелгән вазыйфаи затның яисә вазыйфаи затларның, шулай ук тикшерү үткәрү өчен җәлеп ителә торган экспертларның, экспертлык оешмалары вәкилләренең фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре, вазыйфалары;

- аларга карата тикшерү үткәрелә торган юридик затның аталышы яисә шәхси эшкуарның фамилиясе, исеме, атасының исеме, юридик затларның (аларның филиалларының, вәкиллекләренең, аерымланган структур бүлекчәләренең) урнашу урыннары яисә шәхси эшкуарларның фактта эшчәнлекләрен гамәлгә ашыру урыннары;

- тикшерүнең максатлары, бурычлары, предметы һәм аны үткәрү вакыты;

- тикшерүне үткәрүнең хокукый нигезләре;

- тикшерелергә тиешле зарури таләпләр;

- тикшерүне үткәрүнең максатларына һәм бурычларына ирешү өчен зарури булган контрольлек чараларын үткәрү вакытлары һәм аларның исемлеге;

- дәүләт контролен (күзәтчелеген) үтәү буенча административ регламентлар исемлеге;

- тикшерүне үткәрүнең максатларына һәм бурычларына ирешү өчен юридик затлар, шәхси эшкуарлар тарафыннан тапшырылырга тиешле документлар исемлеге;

- тикшерүне үткәрә башлау һәм тәмамлау даталары;

- министрның, министр урынбасары боерыгының (әмернамәсенең) типик рәвешендә каралган булса, бүтән белешмәләр.";

5.3.4.3 пунктчасының беренче абзацында "2.4.2 пунктының 2 пунктчасындагы "а" һәм "б" пунктчаларында" сүзләрен "2.4.2 пунктының 2 пунктчасындагы икенче һәм өченче абзацларда" сүзләренә алмаштырырга";

5.3.5.1 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"5.3.5.1. Җаваплы башкаручы планлы тикшерүне үткәрә башлау турында министр (министр урынбасары) боерыгының (әмернамәсенең) күчермәсен кулга тапшыру турында хәбәрләмә белән почта аша заказлы хат җибәрү юлы белән һәм (яисә) көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган һәм юридик затның, шәхси эшкуарның электрон почта адресына җибәрелгән электрон документ рәвешендә, әгәр дә мондый адрес тиешенчә бердәй дәүләт юридик затлар реестрында, бердәй дәүләт шәхси эшкуарлар реестрында булса, яисә элегрәк юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан Министрлыкка тапшырылган булса, яисә бүтән үтемле ысул белән социаль хезмәтләрне җиткерүчегә планлы тикшерү үткәреләчәге хакында хәбәр итә.

Үтәү вакыты: юридик затка, шәхси эшкуарга хәбәр итү – тикшерүне үткәрә башларга кимендә өч эш көненнән дә соңга калмыйча.";

5.3.5.2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"5.3.5.2. Җаваплы башкаручы социаль хезмәтләрне җиткерүчегә планнан тыш урынга чыгып тикшерү үткәреләчәге турында, шушы Административ регламентның 2.4.2 пунктында күрсәтелгән нигезләрдә үткәрелә торган планнан тыш урынга чыгып тикшерүдән кала, теләсә нинди үтемле ысул белән, шул исәптән көчәйтелгән

квалификацияле электрон имза белән имзаланган һәм юридик затның, шәхси эшкуарның электрон почта адресына җибәрелгән электрон документ рәвешендә хәбәр итә, әгәр дә мондый адрес тиешенчә бердәй дәүләт юридик затлар реестрында, бердәй дәүләт шәхси эшкуарлар реестрында булса, яисә элегрәк юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан Министрлыкка тапшырылган булса.

Үтәү вакыты: юридик затка, шәхси эшкуарга хәбәр итү – тикшерүне үткәрә башларга кимендә егерме дүрт сәгать калганчыга кадәр.";

5.4.3.1 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"5.4.3.1. Шушы Административ регламентның 2.4.2 пунктында күрсәтелгән очраклар планнан тыш урынга чыгып тикшерү үткәрү өчен нигез булып тора.";

5.4.4.4 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

"Җаваплы башкаручы юридик затның җитәкчесен, бүтән вазыйфаи затын яисә вәкаләтле вәкилен, шәхси эшкуарны, аның вәкаләтле вәкилен ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алынган документлар һәм (яисә) мәгълүматлар белән таныштыра.";

5.4.4.5 пунктчасында ", Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеле торган тәртиптә" сүзләрен төшереп калдырырга;

5.4.4.6 пунктчасында түбәндәге сүзләрне өстәргә:

"Урынга чыгып тикшерү үткәргәндә юридик заттан, шәхси эшкуардан документар тикшерү үткәрү барышында алар тарафыннан тапшырылган документларны һәм (яки) мәгълүматларны таләп итү тыела.";

түбәндәге эчтәлекле 5.4.5.7 пунктчасын өстәргә:

"5.4.5.7. "Әгәр дә шәхси эшкуарның, аның вәкаләтле вәкиленең, юридик зат җитәкчесенең яки башка вазыйфаи затының булмавына бәйле рәвештә, яисә юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан эшчәнлекнең фактта башкарылмавына бәйле рәвештә, шәхси эшкуарның, аның вәкаләтле вәкиленең, юридик зат җитәкчесенең яки башка вазыйфаи затының бүтән төрле, тикшерүне үткәрү мөмкинлеген юкка чыгаручы гамәлләре (гамәл кылмавы) аркасында планлы яки планнан тыш урынга чыгып тикшерүне үткәрү мөмкин булмаса, җаваплы башкаручы, аны үткәрү мөмкинлеген юкка чыгаручы сәбәпләрне күрсәтеп, тиешле тикшерүне үткәрүнең мөмкин булмавы хакында акт төзи. Бу очракта Министрлык, тиешле тикшерүне үткәрүнең мөмкин булмавы хакында акт төзелгән көннән башлап өч ай дәвамында, мондый юридик затка, шәхси эшкуарга карата, планлы тикшерүне еллык планлы тикшерүләр планына кертмичә һәм юридик затка, шәхси эшкуарга алдан хәбәр итмичә, планлы яки планнан тыш урынга чыгып тикшерү үткәрү турында карар кабул итәргә хокуклы.";

Административ регламентка 2 нче кушымтаны төшереп калдырырга.